СОВЕТ НОВОРУССКО-МАМАТКОЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ЯҢА РУС МӘМӘТХУҖАСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

18.07.2018 с. Старое Русское Маматкозино 37-178

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Уставы проекты турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗа авыл җирлеге Советының 2016 елның 16 декабрендәге 19-89 номерлы карары белән расланган Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге башлыгы тәкъдим иткән Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Уставы проектын хуплап, аны беренче укылышта кабул итәргә һәм, тәкъдимнәрне, төзәтмәләрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аның өстендә эшләүне дәвам итәргә (1 нче кушымта).

2. Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Уставы проекты буенча тәкъдимнәрне кабул итү, исәпкә алу һәм карау буенча эш төркеме түбәндәге составта төзергә:

- эш төркеме рәисе, Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге башлыгы В.В.Никитушкин;
- Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлегенең эш төркеме секретаре, башкарма комитеты секретаре В.Р. Камалетдинова;

Эшче төркем әгъзалары:

- Саттарова Алефтина Георгиевна-мәдәният йорты мөдире
- Әхмәдиева Фәридә Фәрит кызы - «Сибгатов Р.» КФХ-хисапчы
- Матвеева Валентина Николаевна-пенсионер

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Уставы проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга. (2 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Уставы проекты буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен расларга. (3 нче кушымта).

5. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге проекты буенча халык алдында тыңлауларны 2018 елның 06 августында Югары Ослан муниципаль районының Мәмәтхуҗа авылы мәдәният йортында 10.00 сәгатьтә Иске Рус Мәмәтхуҗасы авылы, Дорожная ур., 1 йорт адресы буенча үткәрергә.

.

6. Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлегендә яшәүчеләрнең кергән тәкъдимнәрен гомумиләштерергә һәм аларны Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Советына карауга кертергә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру.

8. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Советының законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге башлыгы В. В. Никитушкин